**Шәһәр күләмендә Татарстан һәм татар халкы тарихы фәненнән үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы сораулары 2017-18 уку елы**

**11 нче сыйныф.**

Әзерләнү өчен 3 сәгать вакыт бирелә.
Иң югары – 46 балл.

**1 бүлек. Тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алыгыз. 5 биремгә 1 әр балл (иң югары - 5 балл).**

1. **Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү турындагы Декрет кайчан игълан ителә?**

А) 1919 елның 11 маенда
Б) 1920 елның 15 августында
В) 1920 елның 27 маенда
Г) 1921 елның 11 мартында.

2. **Идел һәм Урал буе төбәгендә массакүләм ачлык кайсы елларда була?**

А) 1920-1921 Б) 1921-1922 В) 1922-1924

**3. Түбәндәге шәхесләрнең кайсысы Казан университетында белем алган?**

А) Гыйлем Камай
Б) Каюм Насыйри
В) Ризаэтдин Фәхретдин
Г) Газиз Гобәйдуллин

**4. Түбәндәге раслауларның кайсысы дөреслеккә туры килә?**

А) 1927 елда Казан киностудиясендә “Булат батыр” дигән беренче һәм бердәнбер нәфис фильм төшерелә.
Б) 1927 елда Татар дәүләт филармониясе ачыла.
В) 1939 елда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле оештырыла.
Г) 1945 елда Татар дәүләт опера театры ачыла.

**5. Александр Матросовның тиңдәшсез батырлыгын кабатлаган сугышчы:**

А) П. Гаврилов Б) Б. Шәвәлиев В) Г. Сафиуллин.

**2 бүлек. Туры китерүгә нигезләнгән биремнәр (вакыйга – дата, автор – әсәр һ.б.). 5 бирем, 2 шәр балл, иң югары балл - 10.**

**6.Язучыны һәм аның сугыш турындагы әсәрен туры китерегез.**

| **Автор** | **Әсәр** |
|---|---|
| 1) Ф.Кәрим | А) “Дустым кабере янында” |
| 2) Г.Бәширов | Б) “Сержант Хәйруллин” |
| 3) А.Шамов | В) “Миңлекамал” |
| 4) М.Әмир | Г) “Разведчик язмалары” |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

**7. Вакыйга һәм датаны туры китерегез**

| **Дата** | **Вакыйга** |
|---|---|
| 1) 1993 | А) Татарстан Республикасының беренче Президенты сайлана |
| 2) 1991 | Б) Татарстан Республикасы Конституциясе кабул ителә |
| 3) 1992 | В) Татарстан Республикасы Дәүләт гимны кабул ителә |
| 4) 2005 | Г) Казан шәһәренең 1000 еллыгы бәйрәм ителә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

**8. Фән, сәнгать һәм мәдәният әһелләренең исемнәрен аларның эшчәнлек өлкәләре белән туры китерегез.**

| **Исем** | **Эшчәнлек өлкәсе** |
|---|---|
| 1) Әбүбәкер Терегулов | А) рәссам |
| 2) Әнвәр Бакиров | Б) композитор |
| 3) Илдар Ханов | В) медицина галиме |
| 4) Мәдинә Маликова | Г) язучы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

9. **Вакыйга һәм датаны туры китерегез**.

| **Дата** | **Вакыйга** |
|---|---|
| А) 2013 | 1) Казан Кремле ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирас объектлары исемлегенә кертелә |
| Б) 1987 | 2) Казанда “Алтын мөнбәр” халыкара мөселман кино фестивале үткәрелә башлый |
| В) 2000 | 3) Казанда Универсиада уеннары узды |
| Г) 2005 | 4) Р.Нуриев ис. Беренче халыкара классик балет фестивале ачыла |

| А | Б | В | Г |
|---|---|---|---|
| | | | |

**10. Авторларны һәм аларның әсәрләрен туры китерегез.**

| **Әсәр** | **Автор** |
|---|---|
| А) “Җәлил” операсы | 1) Р.Яхин |
| Б) “Шүрәле” балеты | 2) Р.Кәлимуллин |
| В) Татарстан гимны | 3) Ф.Яруллин |


| | |
|---|---|
| Г) “Ерактагы кәккүк  авазы” рок-операсы | 4) Н.Җиһанов |
| | |

| А | Б | В | Г |
|---|---|---|---|
| | | | |

**3 нче бүлек. Рәсемнәр белән эшләүгә нигезләнгән биремнәр**

(Рәсемдә кем сурәтләнгән – 1 б., чор дөрес билгеләнгән – 1 б., әлеге сурәт белән бәйле вакыйга дөрес билгеләнгән – 1 б.; иң югары – 3 балл).

**11. Фотоны карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.**



**Фотода кем сурәтләнгән?**

______________________________________________

**Әлеге фотосурәт кайсы чорга карый (унъеллык яки гасырның чирегенә кадәр төгәллек белән)?**

______________________________________________

______________________________________________

**Фотосурәттәге кеше белән бәйле булган тарихи вакыйгаларны атагыз.**

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

**4 нче бүлек. Чыганак текстлары белән эшләүгә нигезләнгән биремнәр.**

**(2 чыганак,  һәрберсенә 3 әр бирем,  һәр биремгә 2-4 балл; иң югары – 18 балл).**

**12. Чыганактан өзекне укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**

[...] Дошманга каршы киң массаны туплауда матур әдәбиятның роле зур. Җанлы сүз, сәнгать сурәте, тапкыр фикерләр гәүдәләндерү аша халкыбызның батырлыгы, ихтыяри көче, булдыклылыгы, Ватанга һәм иптәш (...)га бирелгәнлеге яктыртыла. Матур әдәбият халкыбызның илебезгә булган  мәхәббәтен, немец илбасарларына каршы нәфрәтен тирәнәйтүгә ярдәм итә. Матур әдәбият илебез өстенә, героик халкыбыз өстенә төшкән  бөек сынау көннәрендә халыкны рухландырып, аңа җан азыгы биреп тора.

Татар язучылары Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк барлык совет халкы белән бергә гомуми көрәшкә кушылдылар. Алар каләм көче белән дә, кулларына корал тотып та немец вәхшиләренә каршы сугыш алып баралар. Бу еллар эчендә әдәбиятыбыз дистәләрчә яңа әсәр белән баеды. Татар совет халкын патриотизм рухында, социалистик Ватанга мәхәббәт һәм бирелгәнлек хисендә тәрбияли торган шигырьләр, поэмалар, хикәя һәм очерклар мәйданга килде. Бу әсәрләр чынбарлыкка нигезләнеп язылганнар һәм дөреслекләре белән укучыларның игътибарын үзләренә тарталар. (...)нең "Тупчы анты" исемле шигырьләр җыентыгы Гражданнар сугышыннан алып бүгенге көнгә кадәр халык бәхете өчен, аның якты киләчәге өчен намуслы көрәш алып барган совет патриотының рухи көчен сурәтли. [...]

**Чыганакның төрен билгеләгез (2 балл).**

____________________________________________________________

**Чыганакның язылу вакытын билгеләгез. Сез моны кайдан белдегез? Тексттан берничә мисал китерегез. Әдәбиятның роле бүген нидән гыйбарәт дип саныйсыз (бер-ике дәлил)?(4 балл)**

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

**Текстта төшереп калдырылган фамилияләрне языгыз. (3 б.)**

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

**13. Чыганактан өзекне укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**

*[...] Без татар телен башка телләрдән өстен куярга теләмибез. Ләкин аның бик борынгы һәм бай тел булуы, байтак телләр белән аралашуы, аның күп кенә сүзләре бүтән телләргә күчүе бәхәссез нәрсә.*

*Шулай булгач, бу гүзәл телебезне санга сукмау, белер-белмәс килеш аны "төзәтү", зәгыйфьләндерү, имгәтү фактларына юл куярга мөмкинме соң? Һич мөмкин түгел. Ләкин бездә бу мәсьәләгә гафу ителмәслек җиңел караш яшәп килә. Мин беренче чиратта Казан радиостанциясен күрсәтер идем. Биредә телгә аеруча җавапсыз карыйлар. Иртә белән үк радиодан еш кына "шәхәр", "хәм" дигән сүзләрне ишетергә туры килә.*

*Казан радиостанциясендә эшләүче иптәшләр татар теленнән тулы һәм дөрес файдалану, аны бозмау турында һич уйламыйлар, үзләре белмәгән сүз туры килсә, аны русча гына әйтеп куялар. Сезнең "эремчек" дигән сүзне ишеткәнегез бармы, мәсәлән? Ишетү генә түгел, эремчекнең үзен көн саен ашыйбыз, диярсез. Ә менә радиодан татарча тапшыруларда без еш кына "творог" дигән сүзне ишетәбез. [...] (Г.Беляев. Тагын әдәби телебез турында. 1958).*

**Чыганакның төрен билгеләгез. (2 балл)**

____________________________________________________________

**Өзектә нинди вакыйга турында сөйләнә? Автор билгеләгән проблемаларны атагыз. (2 балл)**

____________________________________________________________

**Сезнең фикерчә, автор күтәргән мәсьәләләр бүген дә актуальме? Телне бозу, тел кагыйдәләрен үтәмәү очракларын бүгенге тормышта кайларда очратырга мөмкин? Аларны төзәтү өчен нәрсәләр эшләргә мөмкин дип саныйсыз? (5 балл)**

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

**5 нче бүлек. Тарихи эссе.**

**14. Түбәндә тәкъдим ителгән темаларның берсен сайлап алып, тарихи эссе языгыз.**
**Күләме – 300 сүз тирәсе.**
**(Теманы дөрес ачкан өчен – 1 балл, тиешенчә китерелгән факт һәм даталар өчен – 2 балл, дөрес аргументлар китергән өчен – 3 балл, төрле карашлар китергән һәм аларга шәхси бәя биргән өчен – 4 балл (иң югары 10 балл).**

1. **“Таш суда йөзә башлаганчы, ә колмак төпкә батканчы...”: болгарларның башка халыклар һәм илләр белән үзара мөнәсәбәтләре.**
2. **Алтын Урдада фән, мәгариф һәм мәдәният.**
3. **Бөек Ватан сугышы чорында Татарстанда сәнгать үсеше.**
4. **Татар мәгърифәтчеләре эшчәнлеге**

**УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!**